ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 54-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 54-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәмmэтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 197-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Һ. Галиев,
Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш); 2024, № 93 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 4 – 6 өлешләр өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«4. Билгеләнгән тәртиптә яңа Вәкаләтле вәкил билгеләп куйганга кадәр вәкаләтләре срогы чыккан Вәкаләтле вәкил үз вәкаләтләрен башкаруны дәвам итә.

5. Вәкаләтле вәкил вәкаләтләре әлеге Законның 6 статьясында билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатылганда, билгеләнгән тәртиптә яңа Вәкаләтле вәкил билгеләп куйганга кадәр булган чорга, эшкуарлар җәмәгатьчелеге фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Вәкаләтле вәкил вазыйфаларын башкаручы билгеләп куелырга мөмкин.

6. Вәкаләтле вәкил вазыйфаларын башкаручыга Вәкаләтле вәкил өчен билгеләнгән таләпләр, чикләүләр һәм тыюлар кагыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы**
**Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Вәкаләтле вәкил) вазыйфага, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил белән килештереп, эшкуарлар җәмәгатьчелеге фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләп куела.

Бүгенге көндә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил булмаган очракта Вәкаләтле вәкил кандидатурасын килештерү мәсьәләсе җайга салынмаган. Закон проекты белән Вәкаләтле вәкилне вазыйфага билгеләп куюны регламентлаштыра торган югарыда күрсәтелгән статьяга, билгеләнгән тәртиптә яңа Вәкаләтле вәкилне билгеләп куйганчы, Вәкаләтле вәкил вәкаләтләрен башкаруны дәвам итүне күздә тота торган нигезләмә өстәү тәкъдим ителә.

Моннан тыш, Вәкаләтле вәкил вакытыннан алда вазыйфасыннан азат ителгән очракта, яңа Вәкаләтле вәкилне билгеләп куйганчы, Вәкаләтле вәкил вазыйфаларын башкаручыны билгеләп кую мөмкинлеге карала.

**«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.